КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 март г.Казань № 152

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 3 март, 130 нчы карары белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 3 март, 130 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 6 декабрь, 940 нчы, 2023 ел, 2 ноябрь, 1406 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 03 март, 130 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 02 март, 152 нче карары редакциясендә)

Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты

I. Дәүләт хезмәтен алучыларның категорияләре (шулай ук ташламалы)

1.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәтен (алга таба - дәүләт хезмәте) алучылар булып кадет мәктәпләрендә һәм гомуми белем бирү хәрби училищеларында 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) тәрбияләнүчеләр, өстәмә гомуми белем бирү, гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү программаларын үзләштерүче иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар, спорт әзерлеге узучы балалар, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар (7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне кертеп)) һәм яшьләр (14 яшьтән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп)) тора (алга таба - дәүләт хезмәтен алучылар).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучыларның ташламалы категориясенә керүчеләр:

хроник авырулары булган, торгызу дәвалавына мохтаҗ 4 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге балалар (шул исәптән ата-аналарының берсе (яки законлы вәкилләре) даими булышлык күрсәтеп торган);

тормышта авыр хәлдә калган балалар, шул исәптән:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге тәрбияләнүчеләре, опекун һәм тәрбиягә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар;

даими булышлык күрсәтеп торыла һәм аннан башка 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар.

II. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

1989 елның 20 ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе тарафыннан расланган Бала хокуклары турында конвенция;

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законы;

«Террорчылыкка каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Иминлек турында» 2010 елның 28 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны тәрбияләүне, укытуны һәм сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;

Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СП СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары;

Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының «Яшәү тирәлеге факторларының кеше өчен иминлеген һәм (яисә) зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләре» СанПиН 1.2.3685-21 санитар кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карары;»

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка актлар.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.

III. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:

| Т/с | Документ исеме | Документны биргән оешма | Гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне раслый торган документ:<br>дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле паспорты | Россия Федерациясе Эчке эшләр министр-лыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| | дәүләт хезмәте алучының туу турында таныклык (14 яшькә кадәрге гражданнар өчен) | гражданлык хәле актларын теркәүче органнар | бирү датасыннан 14 яшь тулганчы |
| | Россия Федерациясе гражданы паспорты (14 яшьтән өлкән гражданнар өчен) | Россия Федерациясе Эчке эшләр министр-лыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| | дәүләт хезмәте алучының хокукларын раслаучы документ яки туганлыкны раслый торган документ | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Чит ил гражданының шәхесен раслаучы документ, яки Россия Федерациясендә чит ил гражданының шәхесен раслый торган документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерация-сенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| | дәүләт хезмәтен алучының законлы вәкиленең шәхесен раслый торган документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерация-сенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| | дәүләт хезмәте алучының хокукларын раслаучы документ яки туганлыкны раслый торган документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерация-сенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән аталыкны билгеләү турында таныклык һәм аның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе (булган очракта) | документның нотариаль расланган тәрҗемәсе | 14 яшькә кадәр |
| 4. | 079/у номерлы форма буенча медицина белешмәсе (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документациясенең унификацияләнгән рәвешләрен һәм аларны алып бару тәртибен раслау турында» 2025 елның 13 маендагы 274н номерлы боерыгы белән расланган) | медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| 5. | Мәҗбүри медицина иминияте полисы | иминият медицина оешмасы | документта күрсәтелгән гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы |

3.2. Документларның төп нөсхәләре тапшырыла. Дәүләт хезмәтен алучының законлы вәкиле тапшырылган документларның дөреслеге өчен закон нигезендә җавап тота.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартларына таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең төп максаты – шәхесне тәрбияләү, белем бирү һәм иҗат потенциалын үстерүне тәэмин итү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология таләпләрен һәм балаларның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү таләпләрен үтәгәндә иҗтимагый файдалы һәм җитештерүче хезмәт, физик культура, спорт, туристлык белән шөгыльләнү.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең төп бурычлары:

дәүләт хезмәтен алучыларның мәгънәле ялын оештыру, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту;

физик культура һәм спорт, туризм белән шөгыльләнү, әйләнә-тирә дөнья һәм табигать турында белемнәрне киңәйтү һәм тирәнәйтү, дәүләт хезмәтен алучыларның

иҗади сәләтләрен үстерү, җәмгыятькә файдалы хезмәтне оештыру, сәламәт яшәү рәвешенә уңай мотивация формалаштыру һәм үстерү өчен дәүләт хезмәтен алучыларда шәхси, иҗади, рухи-әхлакый үсеш өчен кирәкле шартлар тудыру;

дәүләт хезмәтен алучыларны тәрбияләү һәм аларны җәмгыятьтәге тормышка яраклаштыру, үзидарә күнекмәләре, коллективизм һәм патриотизм хисләре тәрбияләү;

дәүләт хезмәтен алучыларда гомумкешелек культурасы һәм кыйммәтләре формалаштыру;

дәүләт хезмәтен алучыларны туристик, туган якны өйрәнү, физкультура-спорт, хәрби-патриотик эшчәнлеккә җәлеп итү.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне Татарстан Республикасы территориясендә һәм Россия Федерациясенең диңгез ярында урнашкан, республика башкарма хакимият органнарына буйсынган балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары (алга таба – Оешмалар) башкара.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тәэмин итү максатыннан Оешмалар түбәндәгеләрне башкара:

Оешмалар тарафыннан дәүләт хезмәтен сыйфатлы күрсәтүне тәэмин итү өчен азык-төлек, эшләр, хезмәтләр һәм башка товарлар сатып алу;

квалификацияле кадрлар туплау;

матди-техник тәэмин итү.

4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү формалары:

Оешмаларда, шул исәптән Россия Федерациясенең диңгез ярындапрофильле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена;

палатка тибындагы лагерьдагы смена.

4.6. Дәүләт хезмәтен алуның календарь чоры:

| Т/с | Дәүләт хезмәте формалары буенча | Алу чоры |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр яны ял лагерындагы смена;<br>шәһәр яны ял лагерында, шул исәптән Россия Федерациясенең диңгез ярында профильле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена;<br>мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьдагы смена;<br>хезмәт һәм ял лагерендагы смена | ел дәвамында каникул чорлары |
| 2. | палатка тибындагы лагерьдагы смена | җәйге каникул чоры |

4.7. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының рәсми сайтында «Россия Федерациясендә баланың хокукларын төп гарантияләү турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җәлеп ителәчәк Оешмалар реестры урнаштырыла.

4.8. Дәүләт хезмәте алучыга азык-төлек һәм медикаментлар белән тәэмин итү нормалары «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 һәм «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар нормалары һәм кагыйдәләре белән билгеләнә.

## V. Дәүләт хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә таләпләр

5.1. Оешмалар дәүләт хезмәтен алучыларга көнкүрешне, ялны һәм сәламәтләнүне, массакүләм, шул исәптән спорт чараларын үткәрүне, медицина ярдәме күрсәтүне, туклануны, хуҗалык-көнкүреш һәм санитария-гигиена хезмәтләрен оештыру өчен кирәкле бүлмәләр, корылмалар белән тәэмин ителергә тиеш, алар санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

5.2. Оешмалар санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормалар, стандартлар, техник шартлар, башка норматив документлар таләпләренә җавап бирә һәм дәүләт хезмәтенең тиешле сыйфатын тәэмин итә торган җиһазлар, аппаратура һәм җайланмалар белән җиһазландырыла.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның йокы бүлмәләре, тору урыннары Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының «Яшәү тирәлеге факторларының кеше өчен иминлеген һәм (яисә) зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләре» СанПиН 1.2.3685-21 санитар кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карарына ярашлы йомшак җиһазлар һәм инвентарь белән тәэмин ителә.

## VI. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең куркынычсызлык таләпләре

6.1. Оешмалар законнар белән билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлергә, Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан балаларның ял һәм сәламәтләндерү оешмаларының төбәк реестрларында булырга тиеш. Әгәр лицензияләү яки рөхсәт таләп итүче эшчәнлек алып барыла икән, Оешмалар тиешле рөхсәтләр яки лицензияләргә ия булырга тиеш.

6.2. Оешмаларның бүлмәләре Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы һәм «Яшәү тирәлеге факторларының кеше өчен иминлеген һәм (яисә) зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләре» СанПиН 1.2.3685-21 санитар кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карарлары белән расланган санитар-эпидемиологик таләпләргә, төзелешкә, эчтәлеккә һәм эшне оештыруга куела торган нормаларга туры килергә тиеш.

6.3. Талпан энцефалиты һәм бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатында Оешмалар ачылганчы урнаштыру районнарында территорияне талпаннарга каршы эшкәртү һәм кимерүчеләргә каршы көрәш чаралары үткәрелә.

6.4. Махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура эксплуатация документларына туры китереп, билгеләнгән максатта гына кулланыла, техник яктан төзек хәлдә тотыла.

Төзек булмаган махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура алыштырыла, төзәтелә (әгәр алар төзәтүгә яраклы булса) яки эксплуатациядән алына.

6.5. Оешмалар түбәндәгеләр өчен билгеләнгән тәртиптә җавап тота:

устав, балаларның ялын оештыру тәртибе һәм Оешмадагы эчке тәртип белән билгеләнгән функцияләрне үтәү;

дәүләт хезмәтен алучыларның тормышы һәм сәламәтлеге;

дәүләт хезмәте алучыларның хокукларын һәм ирекләрен үтәү.

6.6. «Терроризмга каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы һәм «Иминлек турында» 2010 елның 28 декабрендәге 390-ФЗ номерлы федераль законнары нигезләмәләре нигезендә Оешмалар территориясенә керү катгый тыела, дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләрдән тыш.

Килүчеләргә Оешмалар территориясендә исерек хәлдә килү, дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан тиз бозыла торган продуктларны алып килү тыела. Дәүләт хезмәтен алучыларны вакытлыча яисә булуның бөтен чорына бары тик законлы вәкилләр генә, аларның шәхесен таныклый торган документ күрсәтелгәннән соң һәм алар тарафыннан тиешле гариза язылганнан соң гына алырга мөмкин. Башка затлар дәүләт хезмәтен алучыларны аларның шәхесен раслаучы документ һәм нотариаль таныкланган законлы вәкилләрнең ышанычнамәләре күрсәтелгәннән соң гына алып китә ала. Оешмалар территориясеннән чыкканнан соң, законлы вәкилләр дәүләт хезмәтен алучыны талпаннар һәм башка бөҗәкләр булу предметына җентекләп тикшерәләр.

6.7. Оешмалар полицияне ашыгыч чакыру төймәсе белән җиһазландырылган һәм тәүлек әйләнәсе сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта персонал дәүләт хезмәте алучыларны эвакуацияләү һәм коткару белән тәэмин итә. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканнан башлап, аны бетергәнче яки дәүләт хезмәте алучыларны эвакуацияләгәнче, аларны караучысыз калдыру тыела.

6.8. Оешмалар җиһазландырылган булырга тиеш: автоматик янгын сигнализациясе; янгын турында хәбәр итү системасы; кирәкле янгын сүндерү чаралары; шәхси саклану чаралары; эвакуацияне оештыру өчен кирәкле чаралар белән.

6.9. Оешмаларда:

янгын чыккан очракта кешеләрне эвакуацияләү планнары (схемалары) күренеп торган урыннарда эленгән булырга тиеш; персоналның кешеләрне куркынычсыз һәм тиз эвакуацияләүне тәэмин итү буенча гамәлләрен билгеләүче инструкция булырга тиеш;

кимендә ярты елга бер тапкыр Оешманың эвакуациядә катнашучы барлык хезмәткәрләре белән практик күнегүләр үткәрелә.

## VII. Дәүләт хезмәтен алучылар өчен анның мөмкинлеген тәэмин итүче таләпләр

7.1. Дәүләт хезмәтен алучылар һәм аларның законлы вәкилләре турында мәгълүмат, вакыт һәм кабул итү урыны турында барлык мәгълүмат Оешмаларның рәсми сайтында, интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырылган.

7.2. Эш режимы Оешмаларның эчке тәртибе таләпләренә туры китереп билгеләнә.

7.3. Дәүләт хезмәтен алучыларны кабул итү һәм урнаштыру тәртибе Оешмалар тарафыннан расланган ял оештыру уставында һәм тәртибендә билгеләнгән. Дәүләт

хезмәтен алучыларны кабул иткәндә аларны һәм (яисә) дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләрен балаларның ялын оештыру тәртибе һәм Оешмалар эшчәнлеген регламентлаучы башка документлар белән таныштыралар.

7.4. Оешмаларда һәм аларның территорияләрендә дәүләт хезмәтен аерым категория алучыларга һәм аларның законлы вәкилләренә объектлар һәм хезмәтләрнең мөмкинлеген тәэмин итү юлы белән законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шартлар тудырыла.

## VIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителү дәрәҗәсенә таләпләр

8.1. Оешмалар штат расписаниесенә туры килгән квалификацияле белгечләр белән комплектлана.

Оешмалар хезмәткәрләренә җитәкче, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче, педагогик, медицина һәм хезмәт күрсәтү персоналы керә.

8.2. Педагогик һәм хезмәт эшчәнлегенә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары белән педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгәннәр;

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы, җенси кагылгысызлык һәм шәхеснең җенси иреге, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның һәм иҗтимагый әхлакның сәламәтлегенә, дәүләтнең конституциячел корылышы һәм иминлеге нигезләренә, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш) һөкем ителгән яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), әлеге бүлекнең 8.3 пунктында каралган очраклардан тыш;

башка алдан ниятләнгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем карары алынмаган яки көченнән чыгарылмаган;

федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек белән каралган авырулары булган;

чит ил агентлары.

8.3. Шәхеснең тормышы һәм сәламәтлегенә, иреге, намусы һәм дәрәҗәсенә (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, конституцион төзелеш нигезләренә һәм дәүләт иминлегенә, дөнья һәм кешелек иминлегенә, шулай ук җәмәгать иминлегенә каршы зур булмаган авырлыктагы һәм урта авырлыктагы җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар, бу җинаятьләрне кылуда гаепләү буенча җинаять эзәрлекләве акланмаган нигезләр буенча туктатылган затлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең аларны педагогик эшчәнлеккә кертү турында карар булганда педагогик эшчәнлеккә кертелергә мөмкин.

8.4. Җитәкче, педагогик, медицина персоналының квалификациясен күтәрү, эшчәнлек өлкәсенә карап, әлеге вазыйфада эшләгәндә биш елга кимендә бер тапкыр, яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү курсларында укыту һәм (яки) тиешле лицензиягә ия булган белем бирү оешмаларында стажировка үтү юлы белән башкарыла.

8.5. Җитәкче, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче, педагогик һәм хезмәт күрсәтүче персоналның бурычлары җитәкче тарафыннан расланган вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

8.6. Хезмәткәрләр уставны, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтиләр, һөнәри әхлакка иярәләр, үзләренә йөкләнгән функциональ бурычларны намус белән башкаралар, хезмәт гигиенасы һәм җитештерү санитариясе, дәүләт хезмәте алучыларның тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгы таләпләрен, кагыйдәләрен, нормаларын үтиләр.

8.7. Оешмаларның барлык белгечләре тиешле квалификация һәм һөнәри осталык белән беррәттән, югары әхлакый-этик сыйфатларга, җаваплылык хисенә ия булырга,囲 эштә гуманлылык, гаделлек, объективлык һәм игелеклелек принципларына таянырга тиеш. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Оешмалар хезмәткәрләре балаларга максималь сизгерлек, әдәплелек, игътибар, сабырлык, алдан күрүчәнлек, түземлелек күрсәтергә, аларның физик һәм психик халәтен исәпкә алырга тиеш.

## IX. Дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмати тәэмин итү таләпләре

9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат (алга таба – мәгълүмат) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы таләпләренә туры китереп урнаштырыла.

9.2. Дәүләт хезмәте алучылар һәм аларның законлы вәкилләре өчен мәгълүмат Оешмалар тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру, Оешмаларның мәгълүмат стендында урнаштыру һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Оешмаларның рәсми сайтлары аша җиткерелә.

9.3. Оешмалар тарафыннан мәгълүматны гражданнарга җиткерү ысулы, сроклары һәм тәртибе законнарга туры китереп билгеләнә.

9.4. Дәүләт хезмәте алучылар һәм аларның законлы вәкилләре башкарылган дәүләт хезмәте турында кирәкле һәм дөрес мәгълүмат таләп итәргә хокуклы.

9.5. Оешма, дәүләт хезмәтен алучыларга һәм аларның законлы вәкилләренә дәүләт хезмәте турында үз вакытында дөрес мәгълүмат бирергә, дәүләт хезмәтен алу кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга тиеш. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат составына түбәндәгеләр керергә тиеш:

әлеге Стандарт;

дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтен алучылар һәм аларның законлы вәкилләренең дәүләт хезмәте сыйфатына йогынты ясау мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләренең Оешмалар белгечләре белән элемтә чаралары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтен алучылар һәм аларның законлы вәкилләре тарафыннан дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары.

9.6. Оешмаларның эшчәнлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турында мәгълүмат кирәк булган саен, әмма кимендә елга ике тапкыр яңартылырга (актуальләштерелергә) тиеш.

## X. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Дәүләт хезмәтен алучы түбәндәге нигезләрдә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту алачак:

Оешмаларны бетерү яки реорганизацияләү;

дәүләт хезмәтен алучының Оешмаларда ял итүенә комачаулык тудыра торган сәламәтлек торышы турында медицина нәтиҗәсе булу;

дәүләт хезмәтен алучының Оешмаларда тәртип кагыйдәләрен берничә тапкыр (ике һәм аннан да күбрәк) бозуы;

Оешмалардан бәйсез булган форс-мажор хәлләр, ягъни җир тетрәүләр, су басулар, янгыннар, хәрби хәрәкәтләр һәм күзәтчелек органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүгә тыелган гамәлләр.

## XI. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт хезмәте сыйфатының түбәндәге күрсәткечләре белән характерлана:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик күрсәткече | Авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Оешманың штатлы хезмәткәрләр белән комплектлану | процент | $\frac{Ч_ф}{Ч_{шр}} \times 100\%$, монда: $Ч_ф$ – хезмәткәрләрнең фактик саны; $Ч_{шр}$ – штат расписаниесе белән каралган хезмәткәрләре саны | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының статистик күзәтүе формасы | 100 | 7 |
| 2. | Дәүләт хезмәте алучыларның иминлеге | берәмлек | абсолют күрсәткеч (контроль-күзәтчелек органнарын | контроль-күзәтчелек органнары тикшерүләре | 0 | 8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | белән бәйле бозулар | | тикшерү актларында күрсәтелгән хокук бозулар саны) | нәтиҗәләре | | |
| 3. | дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре башка кызыксынган затлар тарафыннан Оешмаларның эшчәнлегенә карата бирелгән нигезле шикаятьләр саны | берәмлек | абсолют күрсәткеч (почта яки электрон почта аша килгән гражданнарның хатлары рәвешендә Оешмага шикаятьләрне һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматларны анализлау нигезендә билгеләнә) | почта яки электрон почта аша килгән гражданнарның хатлары рәвешендә Оешмага шикаятьләрне һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматларны анализлау нигезендә | 0 | 9 |

## XII. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәтенең сыйфат стандарты үтәлмәүгә шикаятьләр бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба - шикаять) кәгазь чыганакта язмача йә Оешмада электрон рәвештә бирелә. Оешмалар җитәкчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Оешмаларны гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органнарына (алга таба - Гамәлгә куючы) бирелә.

12.2. Шикаять почта аша, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәре, Оешмаларның рәсми сайтлары аша электрон элемтә белән җибәрелергә мөмкин, шулай ук дәүләт хезмәте алучының законлы вәкилен Оешма җитәкчеләре яки Гамәлгә куючы вәкиле тарафыннан шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаятьне теркәү Оешманың эш алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә шикаять килгән көннән өч календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

12.4. Шикаять, шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан, теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, Гамәлгә куючыларның, Оешманың вазыйфаи затларының дәүләт хезмәтен алучының законлы вәкилләреннән документлар кабул итүдә баш тартуына карата шикаять белдергән очракта йә җибәрелгән басма хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Оешмалар карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәте алучының

законлы вәкиленә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында язмача һәм, дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле теләге буенча, электрон формада нигезле җавап җибәрә.

12.6. Дәүләт хезмәтен алучының законлы вәкиле дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.

## XIII. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе

13.1. Оешмаларның әлеге Стандартны үтәвен контрольдә тотуны Гамәлгә куючылар тәэмин итә.

13.12. Гамәлгә куючылар ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XIV. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт хезмәте өлешчә түләү шартларында, Татарстан Республикасының агымдагы финанс елы бюджетында бу максатларга каралган акча күләме чикләрендә күрсәтелә.

14.2. Балалар һәм яшьләрнең ял итүе өчен ата-аналар түләвенең минималь күләме, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле финанс елына карарында расланган балалар һәм яшьләрнең ял итүен һәм сәламәтләндерүен оештыру норматив чыгымнарының 15 проценты күләмендә билгеләнә.

Әгәр норматив чыгымнар күрсәтелә торган хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез чыгымнарны чагылдырмаса, Татарстан Республикасы бюджетыннан бүленгән өлеш белән юлламаның фактик бәясе арасындагы аерма дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре тарафыннан түләнә, ләкин юлламаның фактик бәясенең 50 процентыннан артмаска тиеш.

14.3. Юлламаларның бәясе, дәүләт хезмәтен алу өчен ата-аналар түләве турында мәгълүмат Оешмаларның «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендә рәсми сайтларында урнаштырыла.

14.4. Оешмалар торак пунктлардан биш километрдан артык ераклыкта урнашкан очракта, дәүләт хезмәтен алучыларны оешкан рәвештә китерү транспорт оешмалары тарафыннан тәкъдим ителгән бәяләр һәм тарифлар буенча өстәмә түләү белән башкарыла.

14.5. Дәүләт хезмәте агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга каралган акча күләме чикләрендә, 1.2 пунктта күрсәтелгән дәүләт хезмәтен алучыларның ташламалы категорияләре өчен түләүсез күрсәтелә.